СОВЕТ САЛАУССКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САЛАВЫЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**

«28» марта 2023г.

**КАРАР**

№ 73

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Салавыч авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге милкендәге су объектларына ия булу, алардан файдалану, аларны куллану тәртибе турындагы Нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану хакында

Гамәлдәге законнар үзгәрүгә бәйле рәвештә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Салавыч авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Үз көчен югалткан дип тану:

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Салавыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге су объектларына ия булу, файдалану, аларны куллану тәртибе турында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге Советының 27.06.2011 ел, № 31 карары белән расланган Нигезләмә .

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (baltasi.tatarstan.ru) торак пунктлар бүлегендә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Салавыч авыл җирлеге башлыгы — Р.К.Латипов